ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 436 «22» 12 2022 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның 8
декабрендәге № 394 карарына
үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокуратурасының 2022 елның 14 декабрендәге № 02-08-02-2022 номерлы протесты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2021 елның 8 ноябрендәге под-1419/21 номерлы боерыгы, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 21 ноябрендәге 465-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 8 декабрендәге № 394 карары (алга таба – Карар) белән расланган «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына алу турында гаризалар кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче Кушымтаның 1.2.1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган, яисә опекун яки попечитель гаиләсендә, тәрбиягә бала алган гаиләне дә кертеп, яисә Россия Федерациясе закоонарында каралган очракта патронат гаиләдәге, бертуганнары һәм атасы яисә анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) апасы укый торган дәүләт яки муниципаль мәгариф оешмаларына башлангыч гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул итү хокукына ия, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль Законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклардан тыш».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм

00000113

Мамадыш муниципаль районының рәсми www.mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплы итеп Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Хуҗаҗановны билгеләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов